**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлегенең Буралы-Чишмә авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 30 марты** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 3 нче номерлы "«Яңа Имән авыл җирлеге Буралы-Чишмә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Буралы-Чишмә 2023 елның 22 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Буралы-Чишмә торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Буралы-Чишмә авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлегенең Буралы-Чишмә авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 22 ноябрь 2023 елнын 2нче номерлы карарына узгәрешләр кертү турында чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Буралы-Чишмә авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Буралы-Чишмә торак пункты чикләрендә юлларны кардан чистарту (тракторчы хезмәтләре өчен түләү);

3. Коеларны төзү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Буралы-Чишмә авылында шартнамә буенча материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү(МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, );

2. Әлеге карарны Яңа Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Гараев Р.Ф.